МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.12.2018 Казан ш. № 02-151

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 30.12.2015 ел, № 02-144 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетына караган өлешендә Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибен билгеләү, аныклау һәм тәгаенләү турында күрсәтмәләргә үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 30.12.2015 ел, № 02-144 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетына кагылышлы өлешендә Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибен билгеләү, аныклау һәм тәгаенләү турында күрсәтмәләргә (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 30.03.2016 ел, № 02-32, 29.06.2016 ел, № 02-73, 30.09.2016 ел, № 02-116, 27.12.2016 ел, № 02-157, 29.12.2016 ел, № 02-159, 31.03.2017 ел, № 02-30, 30.06.2017 ел, № 02-64, 26.09.2017 ел, № 02-90, 21.12.2017 ел, № 02-129, 26.12.2017 ел, № 02-133, 28.03.2018 ел, № 02-38; 23.07.2018 ел,№ 02-78; 18.12.2018 ел, № 02-138 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) кертелә торган үзгәрешләрне (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Әлеге боерык 2018 елның 26 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Министр Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгының
«26» декабрь, 2018 ел,
№ 02-151 боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 30.12.2015 ел, № 02-144 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетына караган өлешендә Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибен билгеләү, аныклау һәм тәгаенләү турында күрсәтмәләргә кертелә торган үзгәрешләр

1. «Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты чыгымнары исемлеге һәм аларны тиешле максатчан статьяларга кертү кагыйдәләре» 2 пунктта «2013 – 2021 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасы» 2.14. пунктчасында «14 6 06 00000 «Агросәнәгать комплексы объектларын төзүгә һәм модернизацияләүгә тотылган турыдан-туры чыгымнарны компенсацияләү» төп чарасы» максатчан статьясына түбәндәге чыгымнар юнәлешен өстәргә :

«- R4720 Агросәнәгать комплексы объектларын тотуга һәм (яки) модернизацияләүгә тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча агросәнәгать комплексы объектларын тотуга һәм (яки) модернизацияләүгә тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертлар һәм Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга башка бюджетара трансфертларның Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Агросәнәгать комплексы объектларын тотуга һәм (яки) модернизацияләүгә тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» 000 2 02 45472 02 0000 151 коды буенча чагылдырыла.».

2. 2 нче кушымтада
юлдан соң:

| | |
|---|---|
| «14 6 06 65470 | Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә модульле теплицалар сатып алуга бәйле чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү» |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «14 6 06 R4720 | Агросәнәгать комплексы объектларын тотуга һәм (яки) модернизацияләүгә тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга финанслашыла торган чыгымнар». |